| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2021 Баулы шәһәре № 50

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен Баулы муниципаль районына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2020 елның 22 сентябрендәге 5 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү һәм аны норматив җайга салу өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районына бирергә.

2. Әлеге карарны карау өчен Баулы муниципаль районы Советына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә, Баулы муниципаль районы Советы карарын алган вакыттан алып 10 календарь көннән артмаган срокта, төзекләндерү

өлкәсендә вәкаләтләр тапшыру һәм аны норматив җайга салу турында килешү төзүче як буларак эш башкарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән соң) үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының Законлылык, хокук тәртибе, спорт һәм яшьләр эшләре мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф.Корбанов